**Мулла Иле мәктәбе укытучысы**

**Гыйззәтуллина Гөлназ Рухулла кызы**

# “Мин тормышка гашыйк”

Мөгаллим һәм шагыйрь Равил абый Сәйфетдиновның ижатына багышланган әдәби кичә.

**Максат:**

- Укучыларны авылыбызның данлыклы мөгаллим һәм шагыйре Равил абый Сәйфетдиновның тормыш юлы һәм ижаты белән таныштыру,

- Мөгаллимнең әсәрләре аша укучыларда туган илгә, туган җиргә, туган авылларына карата горурлык, мәхәббәт, хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Бизәлеш:** Зал бәйрәмчә бизәлгән, түрдә Равил абый Сәйфетдиновның портреты һәм китаплары күргәзмәсе, тормышын һәм иҗатын яктырткан стендлар, әсәрләренә укучылар ясаган рәсемнәр.

**Чакырылган кунаклар:** Равил абый Сәйфетдиновның тормыш иптәше, балалары һәм оныклары, Равил абый белән бер чорда эшләгән укытучылар.

*Талгын гына “Мулилем” җырының көе агыла.*

**1 нче алып баручы:** Исәнмесез, мөхтәрәм кунакларыбыз, хөрмәтле укытучылар, кадерле укучылар! Хәерле көн!

**2 нче алып баручы:** Кеше гомере – диңгездәге бер тамчы, мәңгелекнең бер мизгеле генә. Шушы кыска гына вакыт эчендә кеше зур-зур планнар кора. Барлык уйлаганын эшләп өлгерергә, җирдә үзенең эзен калдырырга, мәңгелек яшәү алырга тели һәм гомере буе шуңа омтыла.

**1 нче алып баручы:** Бүгенге кичәбезне безнең арабыздан мәңгелеккә киткән авылдашыбыз, мөгаллим һәм шагыйрь **Равил абый Сәйфетдиновның** якты истәлегенә багышлыйбыз.

Яратам мин сине, хезмәт белән
Дан казанган ямьле Мулилем.
Кырларында сине сөюемә
Җавап булып үсә мул иген.

Үрләр сызылып киткән офыкта,
Кояш чыга шулар артыннан.
Яшел Үзән туган бишегем
Алсу нурлар белән манчылган.

Уртасында яшел үзәннең
Җәйрәп ята гүзәл Мулилем.
Кырларында үсә мул иген-
Мәхәббәтем яме шул минем.

Чәчәкләрдәй сибелгәнсең
Матур тау итәгенә.
Ышанамын, шундый авыл
Син берәү икәненә.

Гомер сөрәм Зөя үзәнендә –
Уйсулыкта яткан авылда.
Күләгәле таллар ышыгында
Тирбәләмен йомшак агымда.

Үзән генә, елга гына түгел,
Биргән безгә ходай тавын да.
Тып – тын горур биеклеккә карап,
Көч алам мин хәлсез чагымда.

Гомерләрем шаулап үткән алан,
Керәшәле Зөя ярлары.
Аста сулар ага, язлар саен
Ташкын ашый минем яланны.

Дөньядагы гүзәл бу җәннәтем
Еллар үткән саен тарая.
Яшьлек имәннәрем ташкыннарда
Умырылып төшә ярлардан.

Мулла Иле – минем туган авыл,
Чал тарихта аның үз даны.
Бу бит – шагыйрь Баһаветдин белән
Аның улы Гайнан ватаны.

***(Р.Сәйфетдинов сүзләре, Р. Гатауллин музыкасы "Мулилем")***

**2 нче алып баручы:** Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 елның 14 октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Урта мәктәпне бетергәч, 1956—1961 елларда Казан дәүләт университетында укыган.

1961—1963 елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. Бу урында Әнәс Гайзуллинның "Бердәмлек" газетасында басылып чыккан язмасыннар өзек китерми мөмкин түгел:

"Йомшак күңелле, барлык кешеләрне дә эчкерсез ярата белә торган һәм үзе дә халык тарафыннан бик тә үз ителүче зыялы шәхес булып истә калган ул. Безнең мәктәптә бары ике ел гына эшләгән Равил ага балаларга бөтен көчен биреп, татар, рус, немец телләрен укыткан. Нәкъ менә шушы Гали авылында ул укучылар йөрәгенә юл табу серләренә төшенә, һәр дәрескә иҗат ялкыны белән керә, үзенең максатына ирешә, шуннан үзенә биниһая шатлык, ләззәт ала."

***(Гали авылына багышлап язылган шигырьдән өзекне 1 укучы сөйли)***

**1 нче алып баручы:** 1963—2007 елларда берөзлексез Мулла Иле мәктәбендә хезмәт иткән: авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, алман теле, гарәп теле, дин тарихы фәннәрен укыткан. 1968—1970 елларда — завуч, 1971—2000 елларда мәктәп директоры булган.

**2 нче алып баручы:** Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 елдан алып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифаларын башкарды. 2017 елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

**1 нче алып баручы:** Ә хәзер сүзне Равил абыйның тормыш иптәше һәм балаларына бирәбез. Сүз сезгә хөрмәтле кунакларыбыз.

Мин авылның карт бер мөгаллиме,
Карт мәҗнүне нурлы мәктәпнең.

Кырык еллап эшләп ни күрсәттем,
Кайда эзе минем хезмәтнең?

Торды гомер тоташ сабырлыктан,
Тоташ уйда булды һәр көнем.
Тоташ түздем, бәгырь кыйналса да,
Калдырмадым кеше хәтерен.

Кем дә әйтмәс:”Бер бәхетсез булып,
Иргә түгел, миргә эшләдең.
Шәкертләрең сәлам бирәләрме –
Бигрәк тыйнак, фәкыйрь өстәлең”.

Әйтерсең, мин – авыл читендәге
Япа – ялгыз иске тегермән.
Кимсенмичә һаман тарта бирәм,
Үземә сүз илдән тидермәм.

Үз җиреннән купмас имән кебек,
Түзеп бөтен газап – михнәткә,
Тамырларым туган җиргә берегеп,
Бөтен гомерем үтте мәктәптә.

Кичтем кырык елны бертоташтан,
Офыкларга зарыгып карадым.
Күндәм бурлак кебек җигелеп тарттым
Мәктәп дигән заман корабын.

**1 нче алып баручы:** Равил абыйның шигырьләрендә авылыбыз халкының бөтен яшәеше чагылдырылган. Аның иҗаты беркемне дә битараф калдыра алмый, чөнки ул һәркем өчен кадерле һәм якын булган туган илгә, туган йортка, туган як табигатенә мәхәббәт турында язган.

**2нче алып баручы:** Туган як- ул кешенең туып үскән һәм үзе граждан булып саналган иле, Ватан. Туган як, туган җир дигәндә ни өчендер шәһәр түгел, ә авыл һәм аның бер өлеше булып торган табигать күз алдына килә. Һәрберебезнең дә тамырлары барыбер авылга барып тоташа. Авылның иң күркәм сыйфаты булып аның табигатьтә урнашуы тора.Равил абый да башка әдипләр кебек үк авыл белән табигатьне бербөтен итеп үз шигыръләрендә чагылдыра.

***(Р.Сәйфетдиновның «Авылым җәе», «Туган кырларым» , «Әрә белән Зөя» «Күңелемдә язлар тулы» шигырьләрен сөйләү)***

**1 нче алып баручы:** Иҗатының беренче чорын тәшкил иткән, студент елларында язылган шигырьләренең үзәгендә дөнья бизәкләренә мәхәббәт, сөю-сөелү белән сынау, «аның» килүен көтү, юксыну, шикләнү...
Син янасың тиңсез йолдыз булып,
Җырланмаган җырым иясе.

**2 нче алып баручы:** Алдагы елларда шагыйрь «Мәхәббәт», «Кулларың», «Студент кызга», «Күл буенда» (1960-1961) кебек бөтен барлыгын биләгән сөю хисен, мәхәббәтне олылаган, бу олуг тойгының ямен, тәмен, исен җаныаша уздырган әсәрләрен иҗат итә. Гүзәлен назлы, иң матур сынландыруларга күмгәннән, шикләнү-көнләшүләрен җиңгәннән соң, мондый нәтиҗәгә килә:
Син тормышның үзе кебек чибәр,
Үзе кебек чуар гүзәлем.

***( "Мәңгелек кыз" шигырен сөйләү)***

Кеше дигән бөек исемне гел
Йөрттең Син горур күтәреп.
Яшәмәдең юкны бушка иләп,
Бер дә юкка гомер үткәреп.

Гадилегең белән яраттырдың,
Гадилегең безгә ошады.
Әллә нинди шаян телең белән
Сокландырдың күпме дусларны!

**1 нче алып баручы:** Тормышта үзеннән соң чорлар онытмас тирән эз калдырган шәхесләр бар. Туган җире аларны беркайчан да онытмый, кадерле ядкәр итеп күңел түрендә саклый. Менә шундый шәхесләрнең берсе ул безнең Равил абый.

**2 нче алып баручы:** Равил абый исән булса, тагын бик күп шигырьләр иҗат иткән булыр иде. Үзебезнең кичәбезне Равил абый Сәйфетдиновның "Үзем булып калам" шигыре белән тәмамлыйбыз.

Чыганак: Равил Сәйфетдинов иҗаты турында  Галиуллин Тәлгат Нәби улы, Сайланма әсәрләр, Казан, 2013, 489-510 нче битләр

Равил Сәйфетдиновның тәрҗемәи хәле/Биография Р. Сайфутдинова